ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН
КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

---

ПРИКАЗ БОЕРЫК

___27.09.2017_______ Казань № _____93___

Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы, «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыру максатларында боерык бирәм:

1. Шушы боерыкка кушымтада бирелгән Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Башлыкның беренче урынбасарына, өлешле төзелеш өлкәсендә төзелеше тәмамланган объектларны кабул итү тәртибен күзәтү һәм тикшереп тору бүлеге башлыгына, дәүләт хезмәте күрсәтелүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянып эш итәргә.

3. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Җыелма анализ бүлегенә Регламентны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә кайбер вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында» 2017 елның 02 маендагы боерыгының көчен югалтуын танырга.

5. Бу боерык үтәлүен тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгының беренче урынбасары И.Ф.Сафиуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

**Башлык** **В.А. Кудряшов**

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү
инспекциясенең 2017 елның
«27» сентябрендәге 93 номерлы
боерыгы белән расланды

**Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Бу регламент төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба, тиешенчә – Регламент, дәүләт хезмәте).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар булып түбәндәгеләр тора:

а) өлешле төзелеш объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган очракта:

төзүчеләр – оешу-хокук формасы нинди булуга бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә төзелешне гамәлгә ашыручы, аларга карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы көче туктатылган, мөлкәтләрендә арендалау хокукында, субарендалау хокукында яисә «Төзелешне үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясенең Җир кодексының

39.10 статьясының 2 пунктындагы 5 пунктчасында каралганча түләүсез нигездә файдалану хокукында җир кишәрлеге булган һәм бу җир кишәрлегендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә), төзелешкә алынган рөхсәт нигезендә җитештерү билгеләнешендәге объектлардан кала, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акча чараларын җәлеп итүче юридик затлар.

б) Өлешле төзелеш объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган очракта:

төзүче – хуҗалык җәмгыяте:

шәһәр төзү эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортларны төзүче сыйфатында һәм (яисә) техник заказчы һәм (яисә) генераль подрядчы сыйфатында төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә эксплуатациягә кертүгә алынган рөхсәтләр нигезендә җыеп исәпләгәндә аның яисә аның төп җәмгыятенең яисә төп җәмгыятьнең хуҗалык итүче теләсә нинди җәмгыятенең кимендә гомуми мәйданы ун мең квадрат метрлы шундый күпфатирлы йортларны төзүдә (булдыруда) (кимендә өч еллык) катнашу тәҗрибәсе булган;

мөлкәтендә яисә арендалау хокукында, субарендалау хокукында яки «Төзелешне үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «Төзелешне үстерүгә ярдәм итү турында» Федераль закон), Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясының 2 пунктындагы 5 пунктчасында каралганча түләүсез нигездә файдалану хокукында җир кишәрлеге булган һәм шушы Федераль закон нигезендә шушы җир кишәрлегендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә), җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен төзелешкә алынган рөхсәт нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акча чараларын җәлеп итүче;

аталышында «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре булган.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3.1. Инспекция урнашкан урын: Казан ш., Зур Кызыл ур., 15/9 йорт.

Инспекциянең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30 сәгатьтән алып 17.30 сәгатькә кадәр, җомга 8.30 сәгатьтән алып 16.30 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында «КАИ» яисә «Ирек мәйданы» тукталышларына кадәр килергә кирәк:

10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 83, 89; 91, 98 санлы автобуслар;

2, 3, 5, 7 санлы троллейбуслар.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

Инспекциянең белешмә телефоннары: 237-91-87, 238-34-04.

1.3.2. Инспекциянең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://gsn.tatarstan.ru.

Инспекциянең электрон почта адресы: gsn@tatar.ru.

1.3.3. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Инспекция холлында урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Инспекциянең рәсми сайтында (http://gsn.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Инспекциягә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

4) Инспекциягә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша).

1.3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләренә бәйле барча зарури мәгълүмат төзелеше тәмамланган объектларны кабул итү тәртибен күзәтү һәм өлешле төзелеш өлкәсендә тикшереп тору бүлегендә (алга таба – Бүлек) әзерләнә һәм Инспекция холлындагы мәгълүмат стендында урнаштырыла, шулай ук рәсми сайтта урнаштыру өчен Инспекциянең җыелма анализ бүлегенә тапшырыла.

Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3-2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2001, № 44, 4147 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Торак кодексы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2005, № 1 (1 өл.), 14 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2005, №1 (1 өлеше), 40 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Торак төзелешен үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 161-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2008, № 30 (2 өлеше), 3617 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 3 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 304-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016, № 27 (2 өл.), 4237 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы («Республика Татарстан», 2007, 28 декабрь);

«2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елның планлы чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – № 93-ТРЗ ТР Законы) («Республика Татарстан», 2016, 28 ноябрь);

Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект декларациясе рәвешен раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы (алга таба – № 996-пр боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, http://pravo.gov.ru, 30.12.2016);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

– мөрәҗәгать итүчеләр – шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән билгеләмә нигезендәге төзүчеләр;

– Бүлек – Инспекциянең дәүләт хезмәтен күрсәтү эшен гамәлгә ашыручы, төзелеше тәмамланган объектларны кабул итү тәртибен һәм өлешле төзелеш өлкәсендә тикшереп тору бүлеге;

– дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә

документларны кабул итү һәм тапшыру, мөрәҗәгать итүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

– техник хата – Инспекция тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, бу белешмәләрне кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пункты).

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү.<br>Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә төзелешне гамәлгә ашыручы, аларга карата 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы көче туктатылган төзүчегә күрсәтелә. | № 214-ФЗ Федераль законның 23 статьясының 6 өлешендәге 1.2 пункты |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе | № 304-ФЗ Федераль закон. |
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | – Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының | № 214-ФЗ Федераль законның 23 статьясының 6 өлешендәге 1.2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) (1 нче кушымта);<br>– Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту) (2 нче кушымта). | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр дә туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты | Гаризаны һәм шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң 30 көннән артмаган чорда.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | № 214-ФЗ Федераль законның 19 статьясының 2.1 өлеше |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, | 1. 3 нче кушымтага туры китереп, Инспекция башлыгы исеменә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза.<br>2. Шәхесне таныклый торган документ. | № 214-ФЗ Федераль законның 19 статьясының |

| | | |
|---|---|---|
| шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 3. Төзүче исеменнән персональ белешмәләрне эшкәртүгә рөхсәт бирү вәкаләтен дә күрсәтеп, вәкилнең (әгәр дә мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш йөртсә) вәкаләтләрен раслаучы документ.<br>4. Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы белән расланган формада, Microsoft Excel программасы форматында кәгазь документ яисә электрон рәвештәге проект декларациясе.<br>5. Физик затның 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясының 4 өлешендә билгеләнгән, шушы статьяда күрсәтелгән таләпләргә җавап бирүе турында мәгълүмат.<br>Шушы пунктта күрсәтелгән гариза һәм документлар икешәр нөсхәдә тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәтен алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Инспекциянең рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша | 2 өлеше<br>№ 304-ФЗ<br>Федераль законның<br>6 статьясының<br>5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Юридик зат-төзүчегә карата гомуми файдаланудагы сайтлардан файдаланып, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кысаларында алынырга мөмкин булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшыру хокукына ия булган документлар:<br>– Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>– мөрәҗәгать итүченең салымнарны, җыемнарны һәм башка төрле зарури түләүләрне түләүдә бурычлары булмавы турында белешмәләр;<br>– барлык дәрәҗә бюджетларына узган/агымдагы финанс елында юридик зат тарафыннан фактта түләнгән салымнарның суммасы турында белешмәләр;<br>– бухгалтерлык (финанс) хисапнамәсеннән белешмәләр;<br>– Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан аерым затта күчемсез мөлкәт объектына карата булган хокуклар турында белешмәләр.<br>– Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче тарафыннан объект төзү (булдыру) эше гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлегенә карата белешмәләр;<br>– төзүченең бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затның һәм төзүченең баш бухгалтерының яисә бухгалтерлык исәбенә алып бару бурычы йөкләнгән башка вазыйфаи затның яки төзүченең бухгалтерлык исәбен алып бару буенча хезмәтләр күрсәтү турында аның белән шартнамә төзелгән затның икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен суд хөкеменә тартылмаган булуы турында белешмәләр;<br>– төзүченең бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затның һәм төзүченең баш бухгалтерының яисә бухгалтерлык исәбенә алып бару бурычы йөкләнгән башка | № 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 2 өлеше, 20 һәм 21 статьялары |

| | | |
|---|---|---|
| | вазыйфаи затының яки төзүченең бухгалтерлык исәбен алып бару буенча хезмәтләр күрсәтү турында аның белән шартнамә төзелгән затның икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен алынмаган суд хөкеменә ия булмавы турында белешмәләр;<br>– төзүченең бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затның һәм төзүченең баш бухгалтерының квалификациясеннән мәхрүм ителү рәвешендәге административ җәзага тартылуы турында белешмәләр.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының (җирле үзидарә органнарының) һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны кабул | – Мөрәҗәгать итүченең тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документларны тапшыруы (гаризаның һәм документларның тексты укылышлы түгел; гариза һәм шул исәптән электрон | № 304-ФЗ Федераль законның 6 статьясының |

| | | |
|---|---|---|
| итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | документ рәвешендә җибәрелгән документлар шәхсән яисә электрон имза белән таныкланмаган; документларда язу бетерелгән, өстәп язылган, сүзләр сызылган урыннар һәм аларда килешенмәгән башка төзәтүләр булу)<br>– Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә төзелеш башкаручы, аларга карата 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы көче туктатылмаган төзүченең дәүләт хезмәте күрсәтелү буенча мөрәҗәгать итүе. | 3 өлеше.<br>№ 214-ФЗ Федераль законның 23 статьясының 6 өлешендәге 1.2 пункты,<br>№ 93-ТРЗ ТР Законы. |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>– Инспекция тарафыннан төзүченең № 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә каралган таләпләргә җавап бирмәү фактлары ачыклану.<br>– Инспекция тарафыннан төзүченең проект декларациясенең № 214-ФЗ Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәү фактлары ачыклану.<br>Мөрәҗәгать итүчегә шушы пунктның икенче абзацында каралган нигезләрдә бәяләмә бирелгән очракта яисә мөрәҗәгать итүчегә мондый бәяләмә бирелгән датадан соң 60 көн эчендә аның тарафыннан күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын өлешле төзүдә катнашучының беренчесе белән шартнамәне дәүләт теркәвенә алу буенча документлар тапшырылмаган булса, проект документациясе шушы Регламентта билгеләнгән тәртиптә Инспекциягә яңадан | № 214-ФЗ Федераль законның 19 статьясының 2.2 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | җибәрелергә тиеш. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Рөхсәт алу буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел. | РФ Президентының № 601 Указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен алучының дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән көнне. | |

| | | |
|---|---|---|
| теркәү вакыты | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларын урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү Инспекция бинасы холлында башкарыла, ул һаваны кондиционерлау системасы белән; янгынга каршы система белән; мәгълүмати стенд, документларны рәсмиләштерү өчен зарури җиһазлар белән җиһазланган булырга тиеш.<br>Бинада дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына инвалидлар өчен каршылыксыз үтеп керү тәэмин ителә. Казан ш., З.Кызыл ур., 15/9 йорт адресы буенча урнашкан бинага инвалидларның үтеп керүен тәэмин итү максатларында бина фасадының кирә торган урынында сул яктан 1 метр ераклыкта инвалидлар өчен персоналны чакыртып алу төймәсе урнаштырылган. Шушы төймә аша сигнал бирелгәндә, Инспекция персоналы тарафыннан мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне бина буенча хәрәкәт иттерү гамәлгә ашырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>2) белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар | |

| | | |
|---|---|---|
| затлар белән хезмәттәшлек итүенең саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникатив технологияләрдән файдаланып | кабул итү гамәлгә ашырыла торган биналарның тиешле санда булуы;<br>3) дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәренең мәгълүмат ресурсларында тулы мәгълүмат булу;<br>4) мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен бинага дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыкларсыз үтеп керүен тәэмин итү (бинага һәм аның чикләрендәге бүлмә урыннарына җайлы керү-чыгу).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>3) дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан шушы Регламентны бозуларга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу;<br>4) документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә тапшырганда чиратлар булмау;<br>5) дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булмау;<br>6) инвалидларга аларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итүе күздә тотыла.<br>Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша, дәүләти һәм муниципальхезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтү гамәлгә ашырылмый. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү | Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында консультация Инспекциянең рәсми сайтындагы интернет-кабул итү системасы | |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләре | аша электрон рәвештә алынырга мөмкин.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

### 3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) бирү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

ярашлылык турында бәяләмә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат әзерләү һәм тапшыру;

мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәтен КФҮ, читтән торып эшләү урынында күрсәтү.

техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема шушы Регламентның 4 нче кушымтасында күрсәтелде.

### 3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу буенча Инспекциягә телдән (шәхсән яисә телефон буенча) яисә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта Бүлек белгече мөрәҗәгать итүне консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

Әгәр дә гражданин мөрәҗәгатенә язмача җавап алырга тели икән, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене язмача консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча.

Мөрәҗәгать итүченең телдән мөрәҗәгатенә мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне җавап бирелә.

Язмача мөрәҗәгатькә җавап – мөрәҗәгатьне теркәүгә алган датадан соң утыз календарь көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация; мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

### 3.3. Ярашлылык турында бәяләмә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат әзерләү һәм тапшыру

3.3.1. Ярашлылык турында бәяләмә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) дәүләт теркәвенә алу;

2) Гаризаны карау;

3) Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру (җибәрү) һәм гомуми файдаланудагы сайтлардан мәгълүмат алу;

4) Ярашлылык турында бәяләмә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны формалаштыру;

5) Ярашлылык турында бәяләмә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны тапшыру (җибәрү).

3.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) дәүләт теркәвенә алу.

Мөрәҗәгать итүченең үзе тарафыннан шәхсән яисш ышанычлы заты аша Инспекциягә төзүченең һәм проект декларациясенең № 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү турында гариза (алга таба – гариза) һәм шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларның килүе административ гамәлне башлап җибәрү нигезе булып тора.

3.3.2.1. Бүлек белгече дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.8 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Тапшырылган документлар шушы Регламентның 2.8 пункты таләпләренә җавап бирмәгән очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) баш тарту нигезләренең булуы турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту буенча ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген күрсәтеп, документларны аңа кайтарып бирә.

3.3.2.2. Тапшырылган документлар шушы Регламентның 2.8 пункты таләпләренә җавап биргән очракта документлар белән тәэмин итү һәм тикшереп тору бүлеге белгече:

гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында (алга таба – электрон хөкүмәт) терки;

гаризаны Инспекция башлыгына карау өчен җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә), документларны кабул итүдән баш тарту буенча ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кайтарып бирү яисә электрон хөкүмәт буенча теркәлгән, Инспекция башлыгына карау өчен җибәрелгән ярашлылык турында бәяләмә бирү турында гариза.

3.3.3. Гаризаны карау.

Инспекция башлыгы гаризаны карый һәм аны резолюциясен куеп, Инспекция башлыгының беренче урынбасары юллый.

Инспекция башлыгының беренче урынбасары әлеге гаризаны карый һәм резолюциясе белән аны Бүлек башлыгына юллый.

Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны билгели һәм гаризаны үтәү өчен юллый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: шушы Регламентта билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру (җибәрү) һәм гомуми файдаланудагы сайтлардан мәгълүмат алу.

3.3.4.1. Бүлек белгече дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнарга, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарга, дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында булган оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү эшендә катнашучы бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры китереп белешмәләр алу өчен ведомствоара гарызнамәләр җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән гарызнамәләр.

3.3.4.2. Инспекция гарызнамәләре буенча хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан автоматлаштырылган режимда түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

– гарызанмәне эшкәртү һәм сорала торган белешмәләрне эзләү;

– ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү ярдәмендә сорала торган белешмәләрне формалаштыру, яки, сорала торган белешмәләр булмаган очракта,

сәбәпләрен күрсәтеп, соралучы белешмәләрне баш тарту турында беледерүнамә җибәрү.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара гарызанмә документны һәм мәгълүматларны бирүче органга яисә оешмага килгән көннән соңгы биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яки белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәрләмә.

3.3.4.3. Бүлек белгече гомуми файдаланудагы сайтлардан электрон рәвештә юридик зат-төзүчегә карата түбәндәгечә мәгълүматлар ала:

egrul.nalog.ru Россиянең Федераль салым хезмәте сайтыннан – ликвидацияләнү процедурасыны булуы (булмавы) турында;

kad.arbitr.ru Россия Федерациясе арбитраж судлары сайтыннан – банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсенең алып барылуы турында карар булуы (булмавы) турында, административ җәзага тартылу рәвешендә эшчәнлекнең туктатылуы турында;

old.zakupki.gov.ru Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы сайтыннан – намуссыз җиткерүчеләр реестрында белешмәләр булуы (булмавы) турында, бу реестр «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла;

rnp.fas.gov.ru Россиянең Монополиягә каршы федераль хезмәте сайтыннан – намуссыз җиткерүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрыда белешмәләр булуы (булмавы) турында, бу реестрны алып бару «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла;

torgi.gov.ru Россия Федерациясенең сатуларны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру сайтыннан – җир кишәрлеген сату буенча аукционда яисә җир кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрыда белешмәләр булуы (булмавы) турында.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гомуми файдаланудагы сайтлардан алынган мәгълүматлар.

3.3.5. Ярашлылык турында бәяләмә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны формалаштыру

3.3.5.1. Шушы Регламентның 3.3.4 пунктында каралган административ гамәлләрнең нәтиҗәләре административ гамәлне башлау өчен нигез булып тора.

Бүлек белгече:

гомуми файдаланудагы сайтлардан һәм, шушы Регламентның 3.3.4 пунктына туры китереп, ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибендә алынган документларны (мәгълүматларны) карый һәм анализлый;

мөрәҗәгать итүченең проект декларациясендә булган документларның (мәгълүматларның) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирү фактын билгели;

мөрәҗәгать итүченең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килү фактын билгели;

төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында ярашлылык турында бәяләмә проектын яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.4 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач унбиш календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ гамәлне башкару нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: документларны тикшерү һәм төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында ярашлылык бәяләмәсе турында яисә төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында (дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен шушы Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда) проект әзерләү.

3.3.5.2. Бүлек белгече Бүлек башлыгы, башлыкның беренче урынбасары тарафыннан килештерелгән ярашлылык турында бәяләмә проектын яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат проектын кул кую өчен Инспекция башлыгына юллый.

Инспекция башлыгы ярашлылык турында бәяләмәгә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуга кул куя.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.5.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач өч календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында ярашлылык турында бәяләмә;

төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту.

3.3.6. Ярашлылык турында бәяләмә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны тапшыру (җибәрү).

3.3.6.1. Шушы Регламентның 3.3.5.2 пунктында каралган административ гамәлнең нәтиҗәсе административ гамәлне башлап җибәрү нигезе булып тора.

Бүлек белгече:

ярашлылык турындагы бәяләмәне яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турындагы хатны теркәүгә ала;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә), гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән ярашлылык турында бәяләмәне яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хатны тапшыру датасы һәм вакыты турында җиткерә;

Инспекция сайтында ярашлылык турында бәяләмә бирелүе турында яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турындагы хатны урнаштыра.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән ярашлылык турындагы бәяләмәне яисә, сәбәпләрен күрсәтеп, мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турындагы хатны кулына тапшыра яисә почта аша, хәбәрләмәле заказлы хат итеп җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура шушы Регламентның 3.3.5.2 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

3.3.6.2. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алу буенча мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) шәхсән килгән очракта, Бүлек белгече:

мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) шәхесен билгели, шул исәптән шәхесен таныклаучы документны тикшерә; аның мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен (ышанычнамә) тикшерә;

вәкилгә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) килгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен тапшыру (җибәрү).

### 3.4. Мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәтен КФҮ, читтән торып эшләү урынында күрсәтү

Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза тапшыру эшләре) күпфункцияле үзәктә, КФҮ читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.

### 3.5. Техник хаталарны (язу, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

3.5.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Инспекциягә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шушы Регламентның 5 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза;

б) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хаталары (язу, басма хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган документ;

в) техник хаталар (язу, басма хаталары, грамматик яки арифметик хаталар) булуы турында таныклый торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә киткән техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турындагы гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла яки почта аша хат итеп җибәрелә.

3.5.2. Документлар белән тәэмин итү һәм тикшереп тору бүлеге белгече техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә теркәүгә ала һәм аларны Бүлек белгеченә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кигән вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.5.3. Бүлек белгече:

документларны карый;

техник хаталары булмаган очракта техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар проекты әзерли, аны килештерү өчен Бүлек башлыгына, башлыкның беренче урынбасарына, соңыннан кул кую өчен Инспекция башлыгына җибәрә. Инспекция башлыгы тарафыннан имзаланган һәм теркәлгән техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карарны Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшыра яисә гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта (электрон почта ярдәмендә) аша җибәрә;

дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документларга төзәтмәләр кертү максатларында ярашлылык турында бәяләмә проектын яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат проектын әзерли, шушы Регламентның 3.3.5.2 пунктында каралган гамәлләрне башкара һәм мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә), техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яисә арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен алып калып, кул куйдырып яңартып рәсмиләштерелгән документны тапшыра яисә гаризада күрсәтелгән адрес буенча, Бүлеккә техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яисә арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен тапшырып, документ алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта ярдәмендә) хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) ачыкланганнан соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) җибәрелүе хакында гариза алынганнан соңгы өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп торуның тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи

затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне үз эченә алучы мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүләрне, алар буенча карарлар һәм җаваплар кабул итүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эш башкаруның алып барылышы, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлеше;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүе;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүе.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.2. Хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлүен агымдагы контрольлектә тоту Бүлек башлыгы һәм Инспекция башлыгының беренче урынбасары тарафыннан тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге Инспекциянең структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Үткәрелнән тикшерүләр нәтиҗәсендә, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда гаепле затлар РФ законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшереп тору Инспекция башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Инспекция эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук андагы вазыйфаи затларның һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучы судка кадәрге тәртиптә түбәндәгеләрнең карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) шикаять кылу хокукына ия:

дәүләт хезмәткәрләренең (вазыйфаи затларның) – Инспекция башлыгына.

Инспекция башлыгының – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында караламган түләү таләп ителгәндә;

7) Инспекция, аның вазыйфаи заты дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тапшырылган нәтиҗәсендә җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача формада яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять мөрәҗәгатьитүчене шәхсән кабул итү барышында, КФҮ аша кабул ителергә мөмкин, почта аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, Инспекциянең рәсми сайтыннан (http://gsn.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан файдаланып җибәрелә ала.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять кылына торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең аталышы;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять кылына торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятькә аны тапшырган мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат тарафыннан кул куела.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтен күрсәткән орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында
бәяләмә

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 214-ФЗ Федераль закон) нигезендә түбәндәге объект буенча проект декларациясе каралды:

_______________________________________________________________________
(проект декларациясе нигезендә объектның аталышы)
________________________________________(алга таба – проект декларациясе)
төзүчесе:_______________________________________________________________
(төзүченең аталышы, аның урнашкан урыны, ИНН, ОГРН)
_________________________________________________(алга таба – төзүче),
Инспекциягә 20___ елның «__» __________ килде.

Төзүче һәм проект декларациясе 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап җирә.

Башлык В.А. Кудряшов

Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту**

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 214-ФЗ Федераль закон) нигезендә түбәндәге объект буенча проект декларациясе каралды:

_______________________________________________________________________

(проект декларациясе нигезендә объектның аталышы)

_______________________________________________(алга таба – проект декларациясе)

төзүчесе:_________________________________________________________________

(төзүченең аталышы, анаң урнашкан урыны, ИНН, ОГРН)

_____________________________________________________(алга таба – төзүче),

Инспекциягә 20___ елның «__» __________ килде.

Төзүче һәм (яисә) проект декларациясе[1] 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән түбәндәге таләпләргә җавап бирми[2] (җавап бирмиләр):

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

төзүченең № 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә һәм (яисә) проект декларациясенең № 214-ФЗ Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәвенең ачыкланган фактлары күрсәтелә)

1 кирәкле варианты калдырыла: төзүче һәм проект декларациясе, яисә төзүче, яисә проект декларациясе

2 бер вариант калдырыла

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2.2 өлеше нигезендә Инспекция төзүченең һәм проект декларациясенең № 214-ФЗ Федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе буенча ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

*Бу баш тарту төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе буенча ярашлылык турында бәяләмә алу максаты белән Инспекциягә проект декларациясен яңадан тапшыруда каршылык була алмый.*

Башлык В. А. Кудряшов

Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Кемгә: ________________________________________
____________________________________________
Кемнән: ________________________________
Юридик затның тулысынча аталышы һәм оешу-хокук формасы, түбәндәге исеменнән:
____________________________________________
(җитәкченең яисә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Элемтә өчен мәгълүмат:
Тел.________________________________________
Электрон почта___________________________________
Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) почта адресы:
____________________________________________

**Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза**
**20____ елның «____»________**

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә «Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе буенча ярашлылык турында бәяләмә бирү» дәүләт хезмәте күрсәтелүен сорыйм.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүматлар кушымта итеп бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең ахыргы нәтиҗәсен: кулга
Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә шәхсән тапшыруны һәм (яисә) гаризада күрсәтелгән почта адресына җибәрүне сорыйм.

Шушы гаризаны карау өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) кушымта итеп терким.

Кушымта: (мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган барлык документларны һәм һәр документтагы битләр санын күрсәтергә):

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Имза______________________ _________________________________

(имзаның аңлатмасы)

Дата_________________________

Гариза кабул итеп алынды:
Гаризаны кабул итүгә вәкаләт бирелгән
вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме

Имза_____________________ _________________________________

(имзаның аңлатмасы)

Дата_________________________

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, ябуга, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның ризалыгын раслыйм.

Хәзергесе белән шунысын раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә (мәнфәгатьләр вәкил тарафыннан белдерелгәндә, минем тарафтан вәкил булган затка) кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматларны үз эченә ала.

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

(аталышы, фамилиясе, исеме, атасының исеме), түбәндәге адреста урнашкан:
______________________________________________________________________________.

Бу ризалык белешмәләрне эшкәртү буенча чик вакытларны билгеләми.

Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалыкны кайтарып алу тәртибе миңа мәгълүм.

Персональ мәгълүматларны эшкәртү турында мәгълүмат тапшыру өчен персонал белешмәләләр субъектының элемтә мәгълүматлары, шулай ук законнарда каралган башка очракларда: ________________________(почта адресы) ___________________(телефон) _______________________(электрон почта адресы).

Имза_____________________ ________________________________
(имзаның аңлатмасы)

Дата________________________


Гариза кабул итеп алынды:
Гаризаны кабул итүгә вәкаләт бирелгән
вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме


Имза____________________ ________________________________
(имзаның аңлатмасы)

Дата________________________

Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема




Бүлек белгече
Бүлек белгеченә эшләү өчен гариза җибәрелгән көннән соңгы 3 эш көне эчендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр формалаштыра (җибәрә)
Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнар
Ведомствоара хезмәттәшлек итү аша соратылган белешмәләрне гарызнамә җибәрелгән көннән соңгы 5 эш көне эчендә формалаштыру
Бүлек белгече
Гомуми файдаланудагы сайтлардан Бүлек белгеченә гариза җибәргән көннән соңгы 2 эш көне эчендә электрон формада мәгълүмат ала
Бүлек белгече
Мөрәҗәгать итүче тапшырган мәгълүматларны, ведомствоара хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә һәм гомуми файдаланудагы сайтлардан файдаланып алынган мәгълүматларны анализлый һәм төзүченең һәм проект декларациясенең № 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирү-бирмәвен тикшерә һәм гомуми файдаланудагы сайтлардан белешмәләр һәм ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибендә документлар
Бүлек белгече
Бәяләмә (мондый бәяләмә бирүдән баш тарту) проекты, килештерү өчен Бүлек башлыгына, башлыкның беренче урынбасарына, имза салу өчен Инспекция башлыгына проект әзерләнгән вакыттан башлап 3 календарь көне эчендә җибәрә
Ярашлылык турында бәяләмә (мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту)
Бүлек белгече
ярашлылык турында бәяләмәне (мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны) теркәүгә ала
Бүлек белгече
мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе хакында хәбәр итә
Бүлек белгече
Инспекция сайтында ярашлылык турында бәяләмә бирү (ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту) турында мәгълүмат урнаштыра
Бүлек белгече
мөрәҗәгать итүчегә ярашлылык турында бәяләмә (мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны)

Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йорт-ларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

ТР ДТКИ башлыгы
В.А.Кудряшовка
______________________________
кемнән:
______________________________

**Техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хаталар турында хәбәр итәм
______________________________________________________________________
(хезмәтнең аталышы)

Язылган:______________________________________________________________
______________________________________________________________________

Дөрес белешмәләр:______________________________________________________
______________________________________________________________________

Техник хаталарны төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1. ____________________________________________________________
2. ____________________________________________________________
3. ____________________________________________________________

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны:

e-mail:_______________адресына электрон документ рәвешендә җибәрүне;

___________________________________________ адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, ябуга, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны (мәнфәгатьләр вәкил аша белдерелгәндә, минем вәкилемнең ризалыгын) раслыйм.

Хәзергесе белән шунысын раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә (мәнфәгатьләр вәкил тарафыннан белдерелгәндә, минем тарафтан вәкил булган затка) кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматларны үз эченә ала.

_______________                    __________________ ( __________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)